**Республика Татарстан**
**Исполнительный комитет**
**Пестречинского**
**муниципального района**
422770, с. Пестрецы, ул. Советская, 18

**Татарстан Республикасы**
**Питрәч муниципаль**
**районы**
**башкарма комитеты**
422770, Питрәч авылы, Совет урамы, 18

тел. +7 (84367) 3-02-02 факс: (84367) 3-02-01 E-mail: pitriash@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«30» март, 2023 ел № 233

«Татарстан Республикасы гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү территориаль системасының Питрәч звеносы турында» Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 19 декабрендәге 2393 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе субъектларында гавами хакимият оештыруның гомуми принциплары турында» 2021 елның 21 декабрендәге 414-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасы Конституциясенә үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 26 гыйнварындагы 1-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 19 декабрендәге 2393 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү комиссиясе турында Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- 2 нче кушымтаның 1 бүлегенең 2 абзацында «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисе) сүзләренә алмаштырырга (алга таба - Татарстан Республикасы Рәисе)»;

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы рәсми сайтында http://pestreci.tatarstan.ru һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында: http://pravo.tatarstan.ru Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан (халыкка җиткергәннән) соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Муниципаль район
башкарма комитеты җитәкчесе В.И. Никитин

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ПЕСТРЕЧИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
ИНН 1633605397